СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.11.2023 с. Сарманово № 199

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау, шулай ук Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында» Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының 2014 елның 17 ноябрендәге 169 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында.

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына, Татарстан Республикасының «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставына, Сарман муниципаль районы Советына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 4 пункты нигезендә, карар иттем:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау, шулай ук Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында» Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының 2014 елның 17 ноябрендәге 169 номерлы карарына үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 пунктның 2 нче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәрләрнең үз чыгымнары турында белешмәләр бирмәү, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган белешмәләр бирү, яисә үз чыгымнары турында белә торып дөрес булмаган белешмәләр бирү яисә хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр бирмәү, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган белешмәләр бирү яисә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында дөрес булмаган мәгълүматлар тапшыру, әгәр дә мондый мәгълүматны тапшыру мәҗбүри булса, ул хокук бозу булып тора һәм аларны алмаштырыла торган вазифаларыннан азат итүгә, муниципаль хезмәттән билгеләнгән тәртиптә эштән азат итүгә китерә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль район

Советы рәисе Ф. М. Хөснуллин